КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 сентябрь г.Казань № 788

Ютазы муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 нче пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Ютазы муниципаль районында урнашкан 0,3462 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:43:074901:214 кадастр саны белән ял итү (рекреация) объектларын урнаштыру максатларында махсус сакланыла торган территорияләр җирләре һәм объектлар категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин